Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 ноябрь 2018 ел №261

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Советының 2006 елның 3 февралендә
кабул ителгән №38 "Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы регламенты
турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль Закон, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге №1560-XII Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге № 38 "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы регламенты турында" гы карар кушымтасына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Советының 2009 елның 25 декабрендәге №368, 2014 елның 4 мартындагы №369, 2015 елның 13 мартындагы №456, 2015 елның 10 декабрендәге №33 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 44 маддәнең 5 нче бүлегендә:

а) беренче абзацтагы "электрон почта аша" дигән сүзләрне "бердәм ведомствоара электрон документ системасында электрон документ формасында, электрон почта аша"дип алмаштырырга;

б) икенче абзац итеп түбәндәге эчтәлектәге текст белән тулыландырырга:

"Кеше һәм гражданнарның хокукына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы, җирле үзидарә органнарының, муниципаль предприятие һәм оешмаларның хокукый статусын билгеләүче район Советы карарлары, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрының юнәлтү һәм мәгълүмат җыю өчен җаваплы затка җибәрелә";

1.2. 51 маддәдә:

а) 2 нче бүлеккә икенче абзац итеп түбәндәгеләрне өстәргә;

"Район Советы Федераль Закон, Татарстан Республикасы законнары һәм

район Уставы белән билгеләнгән компетенция чикләрендә, муниципаль норматив актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә кабул итә”:

б) 5,6 нчы бүлекләрне түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга

«5. Район Советының кабул ителгән карар тексты район Башлыгы имза куяр алдыннан карар проектын эшләүче, хокук идарәсе җитәкчесе, структур бүлек җитәкчеләре, әлеге мәсьәләне контрольдә тотучы район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, район башкарма комитеты җитәкчесе (Башкарма комитет вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча) белән килештерелергә тиеш.

Ике дәүләт телендә кабул ителгән норматив хокукый характердагы карар тексты МБУ «Альметьевский вестник» газетасы редакциясе тәрҗемәчесе һәм корректоры белән килештерелергә тиеш.

6. «Альметьевский вестник» газетасы редакциясе муниципаль бюджет учреждениесе тәрҗемәче һәм корректоры ике дәүләт телендә (рус һәм татар) норматив хокукый характердагы карар текстлары тәңгәллеген билгеләүне ике көн эчендә тәэмин итәләр һәм карарларны татар теленә күчерүнең дөреслеге өчен җаваплы булалар.»;

1.3. 53 маддәнең 2 нче бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Карар проекты кабул ителү өчен район Советына бирелгәндә тәкъдим ителергә тиеш:

1) карар проекты тексты;

2) аңлатма язуы;

3) белешмә материаллар (карар проекты буенча мәгълүмат, иллюстратив материал, схемалар, таблицалар һәм башкалар.);

4) финанс-икътисадый нигезләү (әгәр бу проектны гамәлгә ашыру матди чыгымнар таләп итсә);

5) халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары уздыруны раслый торган материаллар: карар проекты буенча халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары билгеләү турында муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару, халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе, халык тыңлаулары, җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә;

6) Әлмәт муниципаль районының Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе (карар проекты тышкы муниципаль финанс тикшерүе предметы булган мәсьәләләргә кагылса);

7) бюджет законнары белән каралган документлар һәм материаллар (район бюджеты турындагы карар проектлары, район бюджеты үтәлеше буенча);

8) әлеге Регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча чагыштырма таблица (район Советының гамәлдәге карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты кертелгән очракта);

9) карар проекты буенча чыгыш ясаучылар һәм чакырылган докладчылар исемлеге;

10) әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә әлеге проектны кабул итүгә бәйле рәвештә карар кабул итәргә, үзгәртелергә, үз көчен югалткан

дип танылырга яки туктатып торырга тиешле муниципаль хокукый актлар исемлеге;

11) район Башкарма комитеты җитәкчесе имзасы »;

1.4. 54 маддәнең 2 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча норматив хокукый характердагы карар проекты билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен «Альметьевский вестник» газетасы редакциясе муниципаль бюджет учреждениесенең тәрҗемәчесе һәм корректорына җибәрелә. «Альметьевский вестник» газетасы редакциясе муниципаль бюджет учреждениесенең тәрҗемәче һәм корректоры проект кергән вакыттан алып өч эш көне эчендә татар теленә карар проекты текстын тәрҗемә итүне тәэмин итәләр. Чираттан тыш сессияләр уздырганда норматив хокукый характердагы карар проектын тәрҗемә итү бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

1.5. 60 маддәне икенче җөмлә белән түбәндәге эчтәлектәге тәкъдим белән тулыландырырга:

«Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү рәвешендә кертелгән очракта, гражданнарның фикер алышуында катнашу тәртибе турында карар проекты буенча тәкъдимнәрне рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) таләп ителми.»;

1.6. 61 маддәне “халык тыңлаулары” дигән сүзләрдән соң “Район Уставына норматив хокукый актлар белән тәңгәл китерү максатыннан Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль Законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Законнары нигезләмәсеннән төгәл күчермәле үзгәрешләр кертелү очракларыннан тыш” сүзләре белән тулыландырырга;

1.7. карарны түбәндәге эчтәлектәге №1 кушымта белән тулыландырырга:

Әлмәт муниципаль районы
Советы Регламентына
№1 кушымта

Әлмәт муниципаль районы Советының карар
проектына чагыштырма таблица
«________________________________»

| Гамәлдәге редакцияле текст | Тәкъдим ителгән үзгәрешләр | Тәкъдим ителгән үзгәрешләрне истә тотып үзгәртелгән текст |
|---|---|---|
| | | |

1.8. карарны түбәндәге эчтәлектәге №2 кушымта белән тулыландырырга:

Әлмәт муниципаль районы
Советы Регламентына
№2 кушымта

Әлмәт муниципаль районы Советы карарлар проекты кабул итү белән бәйле рәвештә кабул ителергә тиешле, үзгәртелергә, көчен югалтты дип саналырга яки туктатылырга тиешле муниципаль хокукый актлар исемлеге

«________________________________»

| № п/п | Кабул ителергә тиешле муниципаль хокукый актлар | Үзгәртелергә тиешле муниципаль хокукый актлар | Кулланылу көче югалды дип саналырга тиешле муниципаль хокукый актлар | Туктатылырга тиешле муниципаль хокукый актлар |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылган көннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны район Советының закон, хокук саклау, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин